Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Бишмунча авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАРЫ

20 март 2024 ел № 3

Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авылы башкарма комитетының 2022 елның 10 мартындагы 3 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Бтшмунча авыл җирлеге башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатен карау һәм кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау тәртибе» турындагы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2024 елның 27 февралендәге 02-01-24/76-2024 номерлы күрсәтмәсен караганнан соң

Бишмунча авыл җирлеге башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 10 мартындагы 3 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатен карау һәм кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау тәртибе» турындагы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- карарага 1 кушымтада:

- 1 нче бүлекнең 1.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Электрон документ формасында кергән мөрәҗәгатьтә тәкъдимнең, гаризаның яисә шикаятьнең асылы бәян ителергә, гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), электрон почта адресы яисә Бердәм порталдагы шәхси кабинетның адресы, әгәр җавап электрон документ формасында җибәрелергә тиеш булса, почта адресы язма формада җибәрелергә тиеш. Гражданнар мондый мөрәҗәгатькә кирәкле документларны һәм материалларны, яисә аларның күчермәләрен язма рәвештә кушымта итеп теркәргә бурычлы.»;

- 4 нче бүлекнең 4.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.9. Гражданнарның коллектив мөрәҗәгатенә язмача җавап, мөрәҗәгатькә кул куйган гражданнарның җавап алучысы яки коллективы вәкиле буларак, мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән шәхси затка җибәрелә. Әгәр җавап алучы коллектив мөрәҗәгатендә билгеләнмәгән булса, җавап мөрәҗәгать итүчеләр (имзалаучылар) исемлегендәге беренче гражданның почта адресына, электрон почтасына яки шәхси кабинетына җибәрелә, әгәр алар күрсәтелмәгән очракта җавап бердәм порталда күрсәтелгән адреска юллана. Әгәр дә коллектив мөрәҗәгатькә җавап җибәрү турында үтенеч берничә мөрәҗәгать итүче (имзаланган) зат тарафыннан белдерелгән булса, җавапның күчермәсе аларның һәрберсенә алар күрсәткән почта адреслары, электрон почта адреслары яки Бердәм порталдагы шәхси кабинет адреслары буенча җибәрелә.»;

- 9 нчы бүлекнең 9.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.5. Гражданнарны шәхси кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә органнарда чираттан тыш шәхси кабул итү хокукына I, II төркем

инвалидлар, инвалид балалар һәм мондый балаларны озата баручы затлар ия.

Әгәр чираттан тыш шәхси кабул итү хокукына бер үк вакытта берничә граждан ия булса, күрсәтелгән гражданнарны кабул итү шәхси кабул итүгә килү тәртибендә башкарыла.

Гражданнарны шәхси кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә органнарда беренче чиратта шәхси кабул итү хокукына түбәндәгеләр ия:

1) Бөек Ватан сугышы ветераннары, Россия Федерациясе Геройлары, Советлар Союзы Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Федерациясе Хезмәт Геройлары, хәрби хәрәкәт ветераннары;

2) ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затлар, шулай ук аларның законлы вәкилләре һәм, әгәр алар мондый балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итсәләр;

3) инвалидларның, инвалид балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итсәләр, I, II төркем инвалидларның, инвалид балаларның законлы вәкилләре һәм инвалид балаларның вәкилләре;

4) өч яшькә кадәрге балалар белән кабул итүгә килгән гражданнар.

Әгәр беренче чираттагы шәхси кабул итү хокукына бер үк вакытта берничә граждан ия булса, күрсәтелгән гражданнарны кабул итү шәхси кабул итүгә килү тәртибендә башкарыла.».

2. Әлеге карарны Әлмәт районы, Бишмунча авылы, Совет урамы, 57 нче А йорт, Кама-Елга авылы, Кама-Елга урамы, 26 а йорт, Ак-Чишмә авылы, Ак-Чишмә урамы, 1 йорт, Бакчасарай авылы, Җиләкле урамы, 1 йорт территориясендә урнашкан махсус стендларда халыкка игълан итәргә, «Татарстан республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Бишмунча авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы — Р.Н.Хәлимуллина